РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.05.2020 № 710-п

“2018-2022 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы балаларына һәм
яшьләренә патриотик тәрбия бирү” муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия биру “муниципаль программасын раслау турында”гы 2018 елның 23 гыйнварында кабул ителгән 53-п номерлы карары белән расланган “2018-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү” муниципаль программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортында “Программаны финанслау күләмнәре” дигән 7 юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

“

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2018-2022 елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 3 125,275 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2018 ел-510,712 мең сум.<br>2019 ел-709,563 мең сум.<br>2020 ел-635,000 мең сум.<br>2021 ел-635,000 мең сум.<br>2022 ел-635,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм ТР Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |

”;

1.2. Программаның 7 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7. Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше.

2018-2022 елларда Программаны Саба муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 3 125,275 мең сум тәшкил итәчәк.

Шул исәптән:

2018 ел-510,712 мең сум.

2019 ел-709,563 мең сум.

2020 ел-635,000 мең сум.

2021 ел-635,000 мең сум.
2022 ел-635,000 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм тиешле финанс елына һәм план чорына Саба муниципаль районы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен анықланырга тиеш”.

1.3. Программаның 1 кушымтасын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**2**. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы И.Р. Гариповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Башкарма комитетының
_______________________________
_______________________________

карарына 1 кушымта

“2018-2022 елларга Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы балаларына һәм
яшьләренә патриотик тәрбия бирү”
муниципаль программасына 1 кушымта

# “2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү” муниципаль программасының төп чаралары

| № п/п | Чаралар исеме | Үткәрү вакыты | Җаваплы башкаручылар | Программаны финанслау күләмнәре еллар буенча, мең сум. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
| **1. Оештыру чаралары** | | | | | | | | |
| 1.1. | Саба муниципаль районы балалары һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү буенча ведомствоара комиссия утырышы (2 кушымта) | Кварталга бер тапкыр | Ведомствоара комиссия әгъзалары | | | | | |
| 1.2. | Районның гомуми белем бирү мәктәпләренең укыту-методик һәм матди-техник базасын ныгыту | даими | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| **2. Яшь гражданнарны патриотик тәрбияләү өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү** | | | | | | | | |
| 2.1. | Балаларга һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирү буенча семинарлар оештыру һәм үткәрү | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ (Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге) | | | | | |
| 2.2. | Бөек Ватан сугышы геройлары, тыл хезмәтчәннәре турында китапларны анализлау буенча уку конференцияләре үткәрү. Рефератлар һәм Иҗади эзләнү-тикшеренү эшләре әзерләү. | ел саен | Мәгариф идарәсе | | | | | |
| 2.3. | “Россия паспорт көне” паспорт тапшыру буенча яшьләр-патриотик акциясен үткәрү | ел саен | РФ Федераль миграция хезмәтенең ТР буенча идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 2.4. | Җәмәгать тәртибен саклау формированиеләренең матди базасын ныгыту | ел саен | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Саба” | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | муниципальара бүлеге ,ЯЭСБ | | | | | |
| 2.5. | “Гражданлык һәм ватанпәрвәрлек сәгате” республика акциясен үткәрү | Кварталга бер тапкыр | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 2.6. | “Ватаныбызны өйрәнеп, үзебезне белербез” - Танылган якташлар, район һәм республиканың тарихы һәм туган якны өйрәнү буенча экспозицияләр циклын оештыру | ел саен | Башкарма комитетның мәдәният бүлеге, район туган якны өйрәнү музее, Мәгариф идарәсе | | | | | |
| 2.7. | Тарихи-туган якны өйрәнү музейларына, мәгариф музейларына экскурсияләр үткәрү һәм аларда катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 2.8. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча мәктәп формированиеләренең республика слетында катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Саба” муниципальара бүлеге | | | | | |
| 2.9. | Балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау отрядларын үстерү буенча эш | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Саба” муниципальара бүлеге | | | | | |
| 2.10. | Кадет сыйныфының уңышлы эшенә ярдәм итү | ел саен | Мәгариф идарәсе, | 11,074 | 9,257 | | | |
| **3. Патриотик тәрбия бирү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар, балалар һәм яшьләр арасында спорт чаралары** | | | | | | | | |
| 3.1. | Көз һәм яз айларында армиягә чакырылырга тиешле хәрби хезмәткә чакырылучыларның Республика спартакиадасын үткәрү һәм анда катнашу. | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.2. | Биш көнлек хәрби-кыр җыеннарын үткәрү | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | 225,739 | 289,895 | 280,000 | 280,000 | 280,000 |
| 3.3. | Саба муниципаль районы хәрби хезмәткә алынучылар арасында хәрби-гамәли спорт төрләре буенча район, зона ярышларын үткәрү һәм аларда катнашу | Апрель, | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.4. | Совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгаруга багышланган чаралар үткәрү | Октябрь | Татарстан Республикасы | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.5. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр формированиеләре спартакиадасын үткәрү | Апрель, Октябрь, ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының “Саба” муниципальара бүлеге | | | | | |
| 3.6. | Хәрби хезмәткә чакырылучыларның физик әзерлеге буенча белем бирү учреждениеләренең смотр-конкурсларын үткәрү | Февраль-Март, ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.7. | Хәрби хезмәткә чакырылучылар көнен үткәрү | Апрель, Октябрь, ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, ЯЭСБ | 108,796 | 194,651 | 150,000 | 150,000 | 150,000 |
| 3.8. | Район спорт ярышлары уздыру:<br>- волейбол буенча ярышлар;<br>- милли көрәш буенча ярышлар;<br>- якташларыбыз-атказанган спортчылар призына, сугышчы-интернационалистлар истәлегенә багышланган чаралар;<br>- Советлар Союзы Геройлары истәлегенә багышланган чаралар һ.б. | ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.9. | Спортның техник төрләрен үстерү (хәрби-гамәли төрләр) | ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.10. | Җиңү көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү | Май, ел саен | Программада катнашучыларның барысы да | 11,521 | 19,240 | 15,000 | 15,000 | 15,000 |
| 3.11. | Батырлык дәресләре үткәрү, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, локаль сугышчыларның, тыл ветераннарының район уку йортларында хәрби дан көненә (җиңү көннәренә) багышланган очрашуларын оештыру. | ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | 9,441 | 10,000 | 10,000 | 10,000 | 10,000 |
| 3.12. | Хәрби дан һәйкәлләре һәм мемориаллары патронажы | ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | | | | | |
| 3.13. | “Аҗаган “ хәрби-патриотик уенын үткәрү | ел саен | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының Саба һәм Теләче районнары буенча бүлеге, Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | 4,046 | 6,840 | 7,000 | 7,000 | 7,000 |
| 3.14. | Якташларыбызның хәрби һәм хезмәт батырлыклары турында материалларны өйрәнү һәм җыю эшен оештыру | ел саен | ЯЭСБ | | | | | |
| 3.15. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (мәктәп) формированиеләре отрядларының район һәм республика конкурсларын үткәрү һәм аларда катнашу | ел саен | Мәгариф идарәсе, ЯЭСБ | 140,095 | 179,680 | 173,000 | 173,000 | 173,000 |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **510,712** | **709,563** | **635,000** | **635,000** | **635,000** |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | **3 125,275** | | | | |